**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА КАЗКЕЕВКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИ-**
**ПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423761, село Казкеево,
ул. Первомайская,дом 2а,
Тел. 3-44-46

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**КӘЗКӘЙ  АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

42361, Кәзкәй авылы,
Беренче май ур., 2 а нчыйорт.
Тел.3-44-46

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
24 февраля 2025 года

**КАРАР**
№ **2**

Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авылы җирлегенең
Тыннамас авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Актаныш муниципаль районының «Кәзкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә, Кәзкәй авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елның 05 мартында 17 сәгать 00 минутка Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең 2024 елның 04 декабрендәге 27 номерлы «Тыннамас авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Актаныш муниципаль районы Кәзкәй авыл җирлегенең 2024 елның 04 декабрендәге 27 номерлы «Тыннамас авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертү белән килешәсезме:
"Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 171 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 94 граждан кертелде.
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен 92 граждан тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен 3 граждан тавыш бирде.
«Тыелып калдылар» позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Тыннамас авылы, Октябрь ур., 72Б;

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районының Кәзкәй авыл башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, Кәзкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында халыкка җиткерергә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Кәзкәй авыл җирлеге башлыгы — Шәйхуллин Р. Р.